**МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**

**Министерство образования и науки Республики Башкортостан**

**МКУ Отдел образования администрации МР Кигинский район РБ**

**МОБУ СОШ с. Еланлино МР Кигинский район РБ**

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
|---|---|---|
| Руководитель ШМО учителей начальных классов | Зам. директора по УВР | Директор |
| ____ШаиховаЛ.Н. | ____Шарафутдинова Г. Л. | ____Шаихова Р. Р. |
| Приказ №5 от «31» 05 23 г. | от «31» 08 23 г. | Приказ №229 от «01» 09 23 г. |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

## учебного предмета «Литературное чтение на родном языке»

для обучающихся 1 – 4 классов

с. Еланлино 2023

## Аңлатма язуы

## 1. Укыту предметының гомуми характеристикасы

Матур әдәбият әсәрләре яшь буынның күңелен, хисләрен баетуда, аларның тирә-яктагы тормышны һәм кешеләрне аңлый башлавында, нәрсәнең яхшы һәм матур, ямьсез һәм начар булуын төшенүдә, зәвыгын тәрбияләүдә, туган халкының рухи дөньясы белән азыклануында бик тә үтемле, көчле тәэсир итүче нигез булып тора. Чөнки әдәбият – сүз сәнгате. Аның шушы зур мөмкинлекләрен тиешенчә файдалану – әдәбият укытуның төп **максаты**.

Хәзерге шартларда матур әдәбиятны сәнгатьнең бик әһәмиятле, нигез төрләреннән берсе итеп укыту мөмкинлекләре бар. Әлеге шартларда әдәбият укытуның эчтәлеген заман таләпләренә туры китерү, камилләштерү һәм яңарту кирәклеге үзәк мәсьәләләрнең берсе булып әверелде. Моны эшләгәндә, гомуми урта белем бирүнең дәүләт стандарты нигез итеп алына, шул ук вакытта аларның таләпләрен тормышка ашыруга иҗади якын килү мөһим.

Укучылар халкыбызның бик бай әдәби мирас үрнәкләре белән таныша башлауның беренче адымнарыннан ук сүз сәнгатебезнең бик тә игелекле, тәэсирле йогынтысында яши, фикерли һәм шул үрнәкләрдә тәрбияләнәләр. Матур әдәбият белем һәм тәрбия бирүдә башка бер фән дә булдыра алмаган мөмкинлекләргә ия. Ул милли үзаң тәрбияли. Әдәбият үз халкының, туган иленең ихлас вәкиле булып формалашуына, ватанының тугрылыклы улы һәм кызы булып яшәүнең асыл мәгънәсен табигый рәвештә күңел хәзинәсе итеп әверелдерүенә китерә.

Әсәр текстларының күбесе балалар әдәбиятының һәм башка әдәби әсәрләрнең иң яхшы үрнәкләреннән сайланып, табигать, кешенең табигатькә мөнәсәбәте, аны саклаудагы роле, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр кебек бүгенге заман проблемаларына туры килә.Әкиятләр, татар халкының мәзәкләре, мәкальләре, әйтемнәре, мәзәкләре табышмаклар һәм тел шомарткычлар укучыларда зирәклек, тапкырлык сыйфатлары тәрбияләүгә өлеш кертә.Кайбер текстлар фольклордан алына, фәнни-популяр текстлардан өзекләр китерелә.

Федераль дәүләт башлангыч белем стандарты нигезендә башлангыч белем бирү төп гомуми белем бирүнең беренче баскычы булып тора. Аның төп максаты – башлангыч белем бирү белән беррәттән, балаларның танып белү активлыгын үстерү, уку эшчәнлеге күнекмәләрен формалаштыруга нигез салу, максат куя һәм аны гамәлгә ашыру юлларын эзли белү, уку нәтиҗәләрен бәяләү күнекмәләрен үстерү. Яңа стандарттагы иң мөһим таләп мондый: мәктәпне тәмамлаганда, **«укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш”**.

Бу – яңа стандартта **эшлекле белем** дип атала**. Эшлекле белем** – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. Белем алу гамәлләренең структурасын һәм принцибын стандарт үзе аңлата.
**Башлангыч сыйныфларында укучы татар балалары өчен төзелгән программа түбәндәге максат һәм бурычларны үз эченә ала:**

1.Укучыларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш, теләк уяту, телеңә мәхәббәт тәрбияләү кебек уңай сыйфатлар булдыру.
2. Балаларда татар теле буенча мәгълүматлылык булдыру.
3. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре булдыру.
4. Хәрефләрдән иҗекләр һәм сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзергә өйрәтү.
5. Укучыларны дөрес һәм матур итеп укырга, укыганның эчтәлеген сөйләргә, аерым   темалар буенча әңгәмәләр кора белергә, аралашканда тел чараларыннан урынлы файдаланырга өйрәтү.
6. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре булдыру.

**Әдәбият белемен өйрәнүгә әзерлек**

1—4 нче сыйныфлар өчен программага бик күп әдәби әсәрләр һәм фольклор материаллары кергән. Сүз сәнгатенең бер төре буларак матур әдәбият белән таныштыра башлау әдәбият белеменнән иң кирәкле төшенчәләрне практик үзләштерүне таләп итә. Дүрт ел дәвамында бу төшенчәләр белән даими таныштыру әдәби текстларга куелган сорау һәм биремнәр ярдәмендә алып барыла
Хикәяләр, андагы вакыйгалар бирелеше. Персонажларның холкы, эш-гамәлләре.
Халык авыз иҗаты. Аның төрләре турында алдагы сыйныфта өйрәнгәннәрне ныгыту.
Әдәп-әхлак темасына багышланган әсәрләрдән яхшы сыйфатларны сайлап ала белү.

**Сөйләм үстерү**

**1—4 нче сыйныфлар өчен әдәби уку программасы 4 ел дәвамында даими рәвештә укучыларның сөйләм телен үстерүгә юнәлтелгән**:
Һәр сыйныфта һәр зур бүлектән соң сөйләм телен үстерү максатында сөйләшү тематикасы бирелгән. Укучылар үзләштергән материалга нигезләнеп, ирекле сөйләшү — диалог оештыру;
укучыларның яшь үзенчәлекләренә туры килердәй текстлар сайлау;
текстлар белән эшләгәндә, укучылар тормышында очраган ситуацияләргә нигезләнеп, кызыклы сораулар бирү;
иҗади эшләргә өйрәтү — хикәя, әкиятләрне дәвам иттерү һ.б.;

әдәби текстның теле укучылар өчен төп материал ролен үти. Әдәби әсәрнең тел үрнәкләренә нигезләнү;

1—4 нче сыйныфлар өчен бирелгән якынча лексик-фразеологик минимумны үтәү.

## 2. Программаны үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр

**1. Әдәби әсәр белән эшләү:**

текстның темасын аңлата белү;
текстны вакыйгасы буенча өлешләргә тарката белү;
сорау куя белү;
укытучы ярдәмендә план төзи һәм шуның буенча эчтәлеген сөйли белү;
укытучы ярдәмендә текстның төп фикерен билгели белү.

**2. Сөйләм телен үстерү:**

үзләштергән материалга нигезләнеп, ирекле сөйләшү-диалог оештыру;
яшь үзенчәлегенә туры килердәй текст сайлау;
бирелгән план буенча эчтәлекне сөйләү;
иҗади эшләргә өйрәнү-хикәя, әкиятләрне дәвам итү, әкиятләр, табышмаклар уйлау;

шигырьләр ятлау.

**3. Әдәбият белемен өйрәнүгә әзерлек:**

сүз сәнгатенең бер төре буларак матур әдәбият белән таныштыра башлау;
әкиятләрнең төп фикере,кызыклы сюжеты һәм композициясе;
әдәби әсәрләрнең темасын, идеясен билгеләргә өйрәтү;
табышмак, мәкаль һәм әйтемнәр,башваткычлар;
төрле сурәтләү чаралары белән таныштыру.

**4. Уку техникасы:**

аңлап, йөгерек, сәнгатьле уку;
кычкырып уку тизлеге – 70 (авыр үзләштерүчеләр өчен) -90-110 (яхшы үзләштерүчеләр өчен) сүздән ким булмау;
эчтән шома уку күнекмәләрен формалаштыру;
укыганны аңлап сөйләргә өйрәтү.

**5. Китап уку белән кызыксыну дәрәҗәсе:**

татар һәм башка милләт язучыларының әкиятләре;
татар классик язучыларының балалар укырга тиешле әсәрләре;
вакытлы матбугат:балалар өчен газета, журналлар белән таныша башлау.

Дөрес, бәйләнешле итеп телдән һәм язма сөйләмгә өйрәтү.

Татар халкының бай әдәби мирасын үзләштерү, халыкның гражданлык һәм мәдәни үткәнен белү яшь буынга аң-белем һәм тәрбия бирү, аларның милли узаңын үстерүдә мөһим роль уйный. Әдәби уку программасына текстларның күбесе балалар әдәбиятыннан һәм әдәби әсәрләрдән сайланып, табигать, кешенең табигатькә мөнәсәбәте, аның табигатьне саклаудагы роле, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр кебек бүгенге заман проблемаларына туры килә. Шактый текст фольклордан алына. Эчтәлеге укучыларга якын булган әкиятләр, татар халкының мәзәкләре, мәкальләре һәм әйтемнәре, табышмаклар һәм телшомарткычлар укучыларда зирәклек, тапкырлык сыйфатлары тәрбияләүгә өлеш кертә

**Әдәбият белемен өйрәнүгә әзерлек**

***1 нче сыйныф***

Әкиятләр, әкият персонажлары, аларның теле, әкиятнең төп фикере. Шигырьләр, алардагы сәнгатьлелекне тою.

***2 нче сыйныф***

Халык авыз иҗаты һәм аның жанрларын аеру. Әкиятләрдәге кызыклы сюжет, композиция. Табышмак, мәкаль  һәм әйтемнәр. Аларга мисаллар китерә белү.

Әдәби әсәрләрдә гомумиләштерелгән образлар, аларның эш-гамәлләре турында сөйли белү. Шигырь, аның сәнгатьлелеге.

***3 нче сыйныф***

Лирик   шигырьләр, шагыйрьнең  хис-тойгылары, сүрәтләү чаралары, чагыштырулар, эпитетлар. Рифма,ритм һәм тон. Лирик шигырьләрне уку барышында матурлыкны шагыйрь күзе белән күрергә өйрәнү.

Язучылар иҗат иткән әкиятләрһәм халык әкиятләренең үзенчәләген аера белү. Тылсымлы әкиятләрдәге предметлар, образлар.

1-2 нче сыйныфларда үзләштерелгән төшенчәләрне ныгыту. Мисаллар китерә белү. Мәзәкләрне аерып карый белү.

Өйрәнелә торган текстларга нигезләнеп, укучыларның сәламәтлегенә игътибар итү.

***4 нче сыйныф***

Хикәяләр, андагы вакыйгалар бирелеше. Персонажларның холкы, эш-гамәлләре.Шигырь, хикәя, әкият, мәзәк жанрларын  аера-таный белү.
Халык авыз иҗаты. Аның төрләре турында алдагы сыйныфта өйрәнгәннәрне ныгыту, системага салу.
Әдәп-әхлак темасына багышланган әсәрләрдән яхшы сыйфатларны сайлап ала белү, шулар үрнәгендә үзеңне тәрбияләү һәм үзеңә бәя бирә алу.

**Укучылар үзләштерергә тиешле гамәлләр:**

- өйрәнелә торган авторның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача күзаллау;
- китап, аның кеше тормышындагы әһәмиятен аңлау һәм үзе өчен кызыклы китап сайлау;
- сүзлекләр белән эшләргә өйрәнү;
- татар телендә балалар өчен чыга торган газета - журналларны белү һәм уку.

**Предметара эшчәнлек алып бару юнәлешләре:**

- әдәбиятны сәнгатьнең башка төрләре белән бәйләп, рәсем, музыка сәнгатьләре турында мәгълүмат бирү;
- туган телнең матурлыгын,байлыгын күрсәтү;
- рус һәм башка халыклар әдәбияты үрнәкләре белән чагыштырып һәм бәйләп укыту;
- әдәби әсәрләрнең һәм халык авыз иҗаты үрнәкләренең темасындагы, образлар бирелешендәге үзенчәлекләрне һәм уртак якларны таба белү.

**Укучының шәхси үсеш-үзгәреше:**

- әдәби әсәрләрдән физик һәм психик сәламәтлеккә бәйле урыннарны табып фикер йөртә белү;
- укучыларда әйләнә-тирәдәге табигатькә, тормышка дөрес мөнәсәбәт формалашу;
- укучыда хезмәткә кызыксыну, теләк уяну;
- әдәби текстка таянып, укучының үз-үзенә бәя бирә алуы;
- укучыда белемгә омтылыш формалашу.

**Башлангыч гомуми белем бирү баскычында (1 - 4сыйныфларда) укучылар үзләштерергә тиешле белем, осталык һәм күнекмәләр**

**Уку техникасы**

***1 нче сыйныф***

Кыска сүзләрне иҗекләп уку. Уку елы ахырына эчтән уку күнекмәләрен формалаштыра башлау.

***2 нче сыйныф***

Аңлап һәм дөрес уку. Эчтән уку һәм сәнгатьле укуның башлангыч күнекмәләрен формалаштыру.

***3нче сыйныф***

Аңлап , дөрес һәм сәнгатьле уку. Йөгерек, сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү: әдәби текстның эчтәлегенә бәйле рәвештә интонациясен, тонын билгели белү.Эчтән уку күнекмәләрен ныгыту.

***4 нче сыйныф***

Аңлап , йөгерек,  сәнгатьле уку.  Эчтән шома уку күнекмәләренә ия булу. Дөрес, тиешле интонацияне һәм тонны сайлап, сәнгатьле уку ярдәмендә текстның эчтәлегенә тирәнрәк төшенү.

**Әдәби текст белән эшләү**

**1 нче сыйныфны тәмамлаганда,  укучы:**

- текст буенча сорауларга җавап бирергә;
- тексттагы сүзләрне кулланып, эчтәлеген сөйли белергә һәм кемнәр катнашуын әйтеп бирә белергә тиеш.

**2 нче сыйныфны тәмамлаганда,  укучы:**

- текстның нәрсә турында булуын аңлата белергә;
- текстны өлешләргә тарката белергә;
- укытучы ярдәмендә план төзи һәм шуның буенча текстның эчтәлеген сөйли белергә;
- башка кеше укыганны тыңлап, эчтәлекне сөйли белергә тиеш.

**3 нче сыйныфны тәмамлаганда,  укучы:**

- тексттагы вакыйга яки төп персонаж буенча аңа исем куя белергә;
- укытучының соравына тексттагы вакыйга яки эпизодны кулланып җавап бирә белергә;
- берничә текстны темасы буенча берләштерә белергә;
- укылган бүлеккә план төзи белергә һәм шуңа язма җавап әзерли белергә тиеш.

**4 нче сыйныфны тәмамлаганда,  укучы:**

- текстны мәгънәви яктан бәйле кисәкләргә бүлә белергә;
- аерым кисәккә исем куя белергә;
- текстның эчтәлеге буенча сораулар куя белергә;
- укытучы ярдәмендә персонажга бәя бирә белергә;
- балалар тормышына якын әсәрләрне мөстәкыйль  рәвештә дәвам итә белергә тиеш.

**1 нче сыйныф.**

Грамотага өйрәтү, үзара тыгыз бәйләнгән укый һәм яза белергә өйрәтүнең башлангыч процессыннан гыйбәрәт аналитик – синтетик аваз – хәреф методы белән тормышка ашырыла; авазлар һәм хәрефләр, иҗекләр һәм сүзләр, җөмләләр һәм бәйләнешле сөйләм өстендә эшләү күнегүләре аша ныгытыла.

**Грамотага әзерлек чоры  түбәндәге  максатка ия:**

- кешеләрнең әйтеп һәм язып сөйләшүләрен гомуми күзаллау.

**Әлифба чоры түбәндәге максатларга ия:**

- Сузык һәм тартык авазлар һәм аларның хәрефләре белән, сүзләрнең калын һәм нечкә әйтелешен билгеләүче калын һәм нечкә сузык аваз хәрефләре белән танышу. Сузык аваз хәрефләренә карап, сүзләрнең калын һәм нечкә әйтеп укылуын күзәтү.
- Кисмә хәрефләрдән һәм кисмә кушылмалардан сүзләр төзү һәм төзелгән сүзләрне кычкырып уку.
- Хәрефләрне дөрес һәм чагыштырмача тиз танып җанлы сүздәге авазлар мәгънәсендә уку.

**Әлифбадан соңгы чор максатлары:**

- нәниләр өчен басылган китаплар белән таныштыру, мөстәкыйль укуга омтылыш булдыру;
- рәсемнәргә карап хикәянең эчтәлеген сөйләү;
- дәрестән тыш укыганны тыңларга гадәтләндерү.

**Грамотага өйрәтү дәресе түбәндәге бурычларны хәл итә:**

- укучыларда сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен үстерү һәм телне аралашу чарасы буларак барлык ситуацияләрдә кулланырга өйрәтү;
- аралашу һәм танып белү чарасы булган телне аңлы үзләштерүгә ирешү;
- балаларны текст, китап белән эш итү алымнарына өйрәтү;
- коммуникатив сөйләм осталыгы һәм иҗади сәләт арасында иҗади бәйләнеш булдыру;
- укучыларның образлы, логик фикерләүләрен үстерү, аларда аралашу культурасы күнекмәләрен тәрбияләү.

## 3. Универсаль уку күнекмәләре.

Әдәби уку буенча төзелгән эш программасы **1 нче сыйныф** укучыларының шәхси үсеш-үзгәреш, предметара һәм предмет нәтиҗәләрен үзләштерүне күз алдында тота.

**Шәхси үсеш-үзгәреш нәтиҗәләренә ирешү осталыгы булып түбәндегеләр санала:**

-гомуми кулланыш нормалары һәм кыйммәтләре күзлегеннән кешеләрнең эш- гамәлләрен, тормыш ситуацияләрен бәяләү;

-текстны “эмоциональ кичерү”, үз фикереңне белдерү;

-башка кешеләрнең хисләрен аңлау,кешенең хәленә керү, аңа теләктәшлек белдерү;

-укылган әсәр геройларына карата үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү;

**Предметара нәтиҗәләр** булып әдәби уку курсын өйрәнгәндә универсаль уку гамәлләре формалашу санала.

| Шәхси универсаль уку гамәлләре. | Регулятив универсаль уку гамәлләре. | Танып-белү универсаль уку гамәлләре. | Коммуникатив универсаль уку гамәлләре. |
|---|---|---|---|
| 1.Түбәндәге кыйммәтләрне аңлый һәм бәяли белү: яхшылык,түземлелек, табигать, туган ил, гаилә һ.б. Үз гаиләңә, туганнарыңа, ата-анаңа хөрмәт.<br>2.Укучы ролен үзләштерү. Укуга карата кызыксыну формалаштыру.<br>3. Гомумкешелек нормалары күзлегеннән чыгып, тормыш ситуацияләрен, геройларның үз-үзләрен тотышларын бәяләү. | 1.Укытучы җитәкчелегендә эш урынын әзерләү, оештыру.<br>2.Укытучы җитәкчелегендә дәрестә, дәрестән тыш эшчәнлектә, тормыш ситуацияләрендә биремнәрне үтәү максатын билгеләү.<br>3.Укытучы җитәкчелегендә дәрестә, дәрестән тыш эшчәнлектә, тормыш ситуацияләрендә биремнәрне үтәү | 1.Китап белән эшләү: бирелгән бүлекне өйрәнгәндә формалашучы белем-күнекмәләрне билгеләү.<br>2.Укытучының гади сорауларына җавап бирү, дәреслектән тиешле мәгълүматны табу.<br>3.Геройларны, аларның гамәлләрен чагыштыру, уртак һәм | 1.Дәрестә һәм тормыш ситуацияләрендә диалогта катнашу.<br>2.Укытучы, сыйныфташларның сорауларына җавап бирү.<br>3.Сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшү, хушлашу,рәхмәт белдерү;<br>4.Башкаларның сөйләмен тыңлап аңлау.<br>5. Парлап һәм күмәк эшләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | планын билгеләү. | аермалы якларын табу.<br>4.Укылган яки тыңланган текстның эчтәлеген сөйләү. | |

**Регулятив универсаль уку гамәлләрен** формалаштыру чарасы булып – продуктив уку технологиясе ; **танып-белү универсаль уку гамәлләрен** формалаштыру чарасы булып-дәреслектәге текстлар, беренчел мәгълүмат белән эшләү күнекмәләрен тәэмин итүче методик аппарат;**коммуникатив универсаль уку гамәлләрен** формалаштыру чарасы булып продуктив уку технологиясе һәм эшне парлап, кечкенә төркемнәрдә оештыру хезмәт итә.

**Предмет нәтиҗәләре:**

-укытучы, укучы укыган текстны ишетеп аңлау;
-бөтен сүзләрне аңлап, дөрес уку;
-текстны тулысынча сөйләү;
-кечкенә күләмле шигырьләрне ятлау;
-рәсем буенча телдән хикәя төзү;
-автор,текст исеме һәм текстның эчтәлеген билгеләү;
-хикәя , шигырьне аера белү.

**Башлангыч сыйныфны тәмамлаганда «Әдәби уку» предметын өйрәтүнең гомуми нәтиҗәләре:**

– катлаулы булмаган монолог төзи белү;
– геройлар һәм вакыйгаларга характеристика бирү;
– укылган әсәрнең эчтәлеген план буенча ачу;
– шигъри әсәрләрне сәнгатьле укый белү;
– иптәшләре алдында кыска чыгышлар ясау;
– дәреслек һәм фәнни-популяр әдәбият белән эшләргә күнегү;
– алган белемнәрне практикада куллана белү;
– укытучы ярдәмендә персонажларга бәя бирә белү;
– төркемнәрдә үз фикерләрен дәлилли белү.

**Универсаль уку гамәлләре**

**Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре**

–Үз илең, халкың һәм тарихың белән горурлану хисләре формалаштыру, һөнәрләр дөньясы белән танышу, җәмәгать урыннарында, мәктәптә үз-үзеңне тотуның әхлакый кагыйдәләрен үзләштерү, аңлы рәвештә рефлексив үзбәя формалаштыру;

– уку эшчәнлеге һәм аның мотивлары арасында элемтә урнаштыру;

– әдәби мәдәният нигезендә матурлыкны күрә белү һәм эстетик хисләр формалаштыру;

**Регулятив универсаль уку гамәлләре**

–максатка ирешүдә үҗәтлек, авырлыкны җиңүгә әзер булу,авырлыкларны чишү ысулларын эзләүгә ихтыяҗ формалаштыру;

–план төзү һәм гамәлләр тәртибен ачыклау;

–ирешеләчәк нәтиҗәне алдан күрү;

–проблеманы чишүдә берничә вариант табу, аларны кулланып карау;

–үтәлгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү, уңышлылыгына бәя бирү;

–кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;

**Танып-белү универсаль уку гамәлләре**

–эшчәнлек барышын һәм нәтиҗәләрен тикшереп һәм бәяләп бару;

– шартлы рәсем, план, күчерү,үзгәртү, төзү;

–охшашлык һәм аермалыкларны аеру, чагыштыру;

–бербөтенне өлешләргә бүлү;

–аерып алынган нигез буенча объектларны тәртипкә салу;

–нәтиҗә чыгару;

–охшашлыклар урнаштыру;

–проблеманы кыска һәм ачык итеп әйтү;

–проблеманы чишү алымнарын хезмәттәшлектә табу;

## Коммуникатив универсаль уку гамәлләре

– укытучы, туганнар, әти-әниләр белән хезмәттәшлекне планлаштыру – катнашучыларның максатларын, вазифаларын үзара аралашу ысулларын билгеләү;

– дискуссиядә катнашу, сораулар формалаштыру, җитмәгән мәгълүматны башкалардан сорашып белү;

– проблеманы ачу, аны тормышка ашыру, үзара килешүгә ирешү;

– эшлекле партнерлы аралашу, төркемдә үзара ярдәм итешү;

– үз фикереңне тулы, төгәл һәм ачык , аңлаешлы итеп әйтү, аны яклау.

**Укучыларның белеменә, эш осталыгына һәм күнекмәләренә таләпләр**

**Укучы белергә тиеш:**

- шигырьләрне сәнгатьле итеп уку;
- әсәрнең мәгънәви кисәкләре арасындагы бәйләнешләрне ачыклау, төп фикерне билгеләү һәм аны үз сүзләре белән әйтеп бирү;
- кыска күләмле әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү;
- тылсымлы һәм хайваннар турындагы әкиятләрне аера белү;
- әсәрдәге төп геройга мөнәсәбәт белдерү;
- укылган әсәрдән чагыштыру, җанландыру, контрастны таба белү;
- 2–3 татар классигының исемен;
- 2–3 хәзерге заман язучысы яки шагыйренең исемен, язган әсәрләрен һәм аларның эчтәлеген;
- үзенә иң ошаган авторның берничә әсәрен;
- китапның төрле элементларына карап эчтәлеген билгеләү;
- сүзлекләрдән кирәкле мәгълүматны табу;
- әсәрләрнең геройларына характеристика бирү, чагыштырулар;
- авторның үз героена мөнәсәбәтен билгеләү;
- яраткан әдәби герое турында сөйли белү;
- дәреслектә дөрес ориентлашу, китап элементларын төгәл билгеләү, авторын, исемен, эчтәлек язылган битне табу, иллюстрацияләр белән эшли белү;
- тематик, монографик  әсәрләр җыентыклары  төзи белү;
- төрле авторларның 6–8 әсәрен яттан белү;
- мөстәкыйль рәвештә китаплар сайлый белү, китап элементлары буенча аның эчтәлеген ачыклау;
- сүзлекләр белән мөстәкыйль эшләү;
- аңлап, йөгерек уку күнекмәләре булдыру;
- текстның темасын, төп фикерен табу, текстны мәгънәви кисәкләргә бүлү, текстның планын төзү, тулы һәм кыскача эчтәлекне бирә белү;
- фольклор әсәрләрен тану, автор әсәрләре белән уртаклыгын, аермасын билгеләү;
- әсәрдәге геройлар турында үз фикерләрен әйтә белүләренә ирешү, геройларның характерын ачыклау, чагыштыру;
- сайлап алып, әсәрне яки бер өзекне яттан өйрәнү; ныгыту;
- дәреслектә оста ориентлашу;
- әсәрдән өзекләр китереп, аннотацияләр язу;
- уку елында өйрәнелгән әдәби әсәрләрнең исемен, авторын, эчтәлеген;

- 1–2 балалар журналын, аның бүлекләрен;
- теге яки бу авторларның китапларын (бирелгән исемлек буенча, чыгыш әзерләү өчен) мөстәкыйль рәвештә китапханәдә сайлый белү, китап элементлары буенча аның эчтәлеген ачыклау;сайланган әсәрләрне мөстәкыйль уку.

## 4. Укытуны тематик планлаштыру
### 1 нче сыйныф

| № | Бүлекләр, темалар. | Программа буенча. |
|---|---|---|
| 1 | **Телдән әзерлек чоры** | 3 сәг. |
| 2 | **Әлифба чоры.** Хәрефләр өйрәнәбез | 18 сәг. |
| 3 | **Әлифбадан соңгы чор. Уку** | 12 сәг. |
| | **Барлыгы** | 33 сәг. |

### 2 нче сыйныф
### Әдәби уку дәресләренең эчтәлеге

| | |
|---|---|
| 1 | Яңа уку елы белән! Г.Тукай иҗаты.”Туган тел” шигыре |
| 2 | З. Туфайлова иҗаты.”Туган ил” шигыре. Рифма турында төшенчә |
| 3 | Р. Вәлиева иҗаты. “Туган җир”шигыре .Пауза. |
| 4 | Г.Галиев “Туган ил кайдан башлана?” |
| 5 | Р.Мәннан иҗаты. “Татарстан флагы” шигыре. |
| 6 | Риваятьләр белән танышу. |
| 7 | “Туган ил ул бер генә, чәчәк кенә, гөл генә” темасын йомгаклау дәресе |
| 8 | Халык авыз иҗаты әсәсрләре. Такмаклар |
| 9 | Халык авыз иҗаты әсәсрләре. Табышмаклар |
| 10 | Халык авыз иҗаты әсәсрләре. Санамышлар |
| 11 | Халык авыз иҗаты әсәсрләре. Мәзәкләр |
| 12 | Халык авыз иҗаты әсәсрләре. Мәкальләр |
| 13 | Халык авыз иҗаты әсәсрләре. Әкиятләр |
| 14 | Көз”шигырендә туган як табигатенә ярату хисе. |
| 15 | Н.Сладков иҗатында кыргый җәнлекләр һәм кошлар тормышы сүрәтләнеше.. |

| | |
|---|---|
| 16 | Туган як табигате турында укыйбыз. Тикшерү эше. |
| 17 | Йолдыз Шәрәпованың “Тылсымлы сүзләр” шигырендә ярату хисе чагылышы. |
| 18 | Ә.Бикчәнтәева иҗаты. “Тәмле сүз” хикәясе |
| 19 | Ш.Галиев иҗаты. “Рәхмәтләр хакында”шигыре. |
| 20 | Р.Гыйззәтуллинның “Тылсымлы сүз”хикәясендә олыларга карата ярдәм итү теләге. |
| 21 | Н.Каштановның “Ачулы туп” хикәясендә геройлар тормышы. |
| 22 | “Балачак мизгелләре” бүлеген йомгаклау биремнәре |
| 23 | Сыйныфтан тыш уку. Г.Тукай “Шүрәле” әкияте. |
| 24 | БСҮ”Туган якның гүзәллеге”. |
| 25 | Шагыйрьләребез иҗатында кышкы табигать сурәтләнеше |
| 26 | Г.Ибраһимовтан “”Кар ява” |
| 27 | Г.Бакир иҗаты белән танышу, “Кышкы уен”хикәясе |
| 28 | Теманы йомгаклау.<br>“Минем туган ягым”хикәя язу |
| 29 | Туган як табигатенең кышкы үзгәрешләре. Җ. Дәрзаман “Җепшек көндә” шигыре |
| 30 | Кышкы урман табышмаклары. |
| 31 | Гәрәй Рәхим “Безнең тауда”. |
| 32 | “Урман читендә” хикәясендә Таңсылу һәм Вәли образлары |
| 33 | “Яңа ел килгәндә”текстын өлешләргә бүлү. |
| 34 | Р.Корбанның<br>“Чыршы бәйрәме” шигырендә балаларның кичерешләре |
| 35 | Җ.Тәрҗеманов “Һай, Кыш бабай!”<br>“Кыш” инша язу. |
| 36 | Хаталар өстендә эш.<br>БСҮ.”Җир ап-ак юрганын ябынган” |
| 37 | Яраткан кошларыбыз һәм хайваннарыбыз. Г. Сәгыйрев “Акбай” шигыре |
| 38 | Р. Вәлиеваның “Ак песи” хикәясендә геройлар |
| 39 | Санамыш, табышмаклар |
| 40 | Безнең урман дусларыбыз. |
| 41 | М. Җәлил иҗаты. “Күке” шигыре |
| 42 | Зиннур Хөснияр “Тукран тәүбәсе” әкияте |

| | |
|---|---|
| 43 | Ә. Бикчәнтәеваның “Үрдәк беренчелекне алган”текстында хайваннарга хас уңай һәм тискәре сыйфатлар бүленеше. |
| 44 | Класстан тыш уку.<br>Ш.Галиев “Колынкаем” |
| 45 | Татар халык әкияте.<br>“Кем нәрсә ярата?” |
| 46 | “Тавык, тычкан һәм көртлек “ әкияте |
| 47 | Дөнья халыклары әкиятләре белән таныштыру |
| 48 | Яз килә, яз көлә.Ә. Бикчәнтәеваның “Апрель ае”шигырендә язгы үзгәрешләр сурәтләнеше. |
| 49 | Язучыларыбыз иҗатында язгы табигатьтәге үзгәрешләр |
| 50 | Агачлар да авырый |
| 51 | Рәхмәт сезгә, ветераннар!<br>Бөек Җиңүгә 70 ел! |
| 52 | Р.Гыйззәтуллин”Миләш нигә әче?” |
| 53 | Теманы йомгаклау.<br>Инша язу.”Туганлык мөнәсәбәтләре”. |
| 54 | Тату гаилә.<br>Г.Тукай “Безнең гаилә” шигыре |
| 55 | З. Воскресенская ”Әни” |
| 56 | “Чәчәк буласым килә”хикәясендә пейзаж. |
| 57 | Р. Мингалимнең “Канатларың булса”хикәясендә хыяллар бирелеше. |
| 58 | И.Юзеев “Дәү әнием” |
| 59 | “Ана рәхмәте”<br>хикәясендә үзәкә куелган төп тема. |
| 60 | Башка халыкларның әкиятләре белән таныштыру.<br>“Боткалы чүлмәк” |
| 61 | Теманы йомгаклау.<br>БСҮ “Әдәпле булырга теләсәң” |
| 62 | Саумы, җәй! |
| 63 | Б.Рәхмәт иҗаты. “Иң күңелле чак” шигыре. |
| 64 | Язучыларыбыз иҗатында җәйге табигать үзгәрешләре. |
| 65 | Л.Лерон “Җәйге бәхәс”. |
| 66 | Кояш безнең дустыбыз.<br>Уку тизлеген тикшерү |

| | |
|---|---|
| 67 | М.Хөсәен “Сабантуй”шигыре. Милли тәрбия үзенчәлекләре. |
| 68 | Елны йомгаклау, тикшерү биремнәрен эшләү. |

**3 нче сыйныф**

**Әдәби уку дәресләренең эчтәлеге**

| | |
|---|---|
| Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр | 2 сәг. |
| Туган як | 3 сәг |
| Килеп җитте кыш та | 3 сәг. |
| Яхшыдан үрнәк ал, яманнан гыйбрәт ал | 3 сәг. |
| Ата – ана һәм туганнар | 3 сәг. |
| Яз | 6 сәг. |
| Әкият сөйлим сезгә. | 7 сәг. |
| Җәй җитте. | 4 сәг. |

**4 нче сыйныф**

**Әдәби уку дәресләренең эчтәлеге**

| № | **Темалар** | **Сәгать саны** |
|---|---|---|
| 1 | Табигать һәм без | 18 |
| 2 | Озын-озак балачак | 14 |
| 3 | Тәрҗемә әсәрләр | 10 |
| 4 | Шигърият дәфтәре | 11 |
| 5 | Халык авыз иҗаты | 15 |

## 4. Әдәби уку дәресләренең эчтәлеге

### 1 нче сыйныф

***<u>Әзерлек чоры (3 сәг)</u>***

Әкият текстын тыңлау. Иллюстрацияләрнең (рәсемнәрнең) текст өлешләре белән бәйләнешен (мөнәсәбәтен) ачыклау. Әкият эчтәлеген сөйләү.

Балаларда текст турында, беренчедән, мәгънә ягыннан үзара бәйләнгән һәм хәбәр итү интонациясе белән әйтелә торган, якынча тәмамланган фикерне белдерүче, билгеле бер эзлеклелектә килгән сүз һәм җөмләләр җыелмасы буларак, икенчендән, нәрсә турында да булса хәбәр итүче һәм ишетеп, күреп зиһенгә алына торган мәгълүмат буларак башлангыч күзаллау булдыру. Иллюстрация темасы буенча җөмләләр төзү. Конкрет җөмләләр белән текстның график моделе арасындагы мөнәсәбәтне ачыклау. Рәсем белән бирелгән

хикәяне исемләү (исем кушу). Текст төзү элементлары. Тәкъдим ителгән график моделе буенча хикәя эчтәлеген сөйләү.
Укылган текст эчтәлеге буенча бирелгән укытучы сорауларына җавап бирү. Текст эчтәлеген сайлап алып сөйләү, шигырь ятлау.
Телнең структур берәмлеге буларак сүз турында башлангыч күзаллау булдыру. Басма хәрефләрнең элемент-өлгеләре белән танышу

***<u>Әлифба чоры(18 сәг)</u>***

Сузык **[а, ә, ы, э, и, у, ү, о, ө]** авазларының сүздә төрле позициядә килгән һәм аерым кулланылган очрактагы артикуляцияләрен ныгыту. Сузык авазларны аеру күнегүләре. Иҗек ясау процессында сузыкларның роле. Сүз кисәге буларак иҗек турында белешмә. График схема буенча сузык авазны әйткәндә, сузыкка басым куеп әйтү. Сүзнең график схемалары буенча сүзне көйләп,иҗекләргә бүлеп салмак һәм орфоэпик дөрес уку. Сүзнең иҗекләргә бүленешен дуга ярдәмендә билгеләү.
Схемада сузык авазны башта түгәрәк, соңыннан транскрипция билгесе белән билгеләү. Ишетелгән һәм әйтелгән сүзләр арасыннан өйрәнелә торган аваз кергән сүзне таный һәм аера белергә өйрәнү. Өйрәнелгән сузык аваз кергән сүзләр сайлау.
Элемент-өлге ярдәме белән басма хәрефләр төзү һәм аларның формаларын үзләштерү. Хәреф турында авазның тышкы билгесе, ягъни «киеме» буларак образлы күзаллау булдыру.
Укытучы укыган текстны тыңлау, эчтәлеген аңлау, куелган сорауларга җавап табу, ишетеп кабул ителгән текстның эчтәлеген тулысынча яки сайлап сөйләү.
Иҗекләр һәм сүзләр, текстлар уку. Текстның эчтәлеген үзләштерү. Эчтәлеген сөйләү. Басма хәрефләрнең формаларын үзләштерү.

***<u>Әлифбадан соңгы чор (12 сәг)</u>***

Төрле жанрдагы текстларны аңлап уку күнекмәләрен формалаштыру. Текстагы «авыр» (озын һәм таныш булмаган) сүзләрне укыганда иҗекләп укырга мөмкин. Җөмләнең тыныш билгеләренә карап җөмләләр арасында тукталыш (пауза) ясау. Хикәяләү, сорау, тойгылы җөмләләрнең интонациясен бирү. Укылган текст буенча бирелгән сорауларга тулы җавап бирү. сайлап алып эчтәлеген сөйләү, текстның башын, ахырын үзгәртү, аңа яңа исем бирә белү күнекмәләренә ия булу.Текстның
**1) башлам** (вакыйга нәрсәдән башалана);
**2) төп өлеш** (катнашучы-геройлар белән нәрсә була);

**3) йомгаклауга** (нәрсә ничек төгәлләнә) туры килә торган кисәкләрен табу һәм уку. Текста сурәтләнгән вакыйгаларга укучы баланың һәм авторның мөнәсәбәтен белдерә белү**.**

**Ятлау өчен әсәрләр**

**Габдулла Тукай.** Әлифба. Гали белән Кәҗә.
**Мөдәррис Әгъләмов.** Бүләк.
**Санамышлар.**
**Гөлшат Зәйнашева.** Бер атнада ничә көн?

**Әңгәмә кору өчен якынча темалар**

*Туган телне өйрәнәбез.
*Безнең гаилә.
*Яраткан кошларыбыз һәм хайваннарыбыз.
*Әдәпле сүзләр.
*Бүген Тукай туган көн.

**1нче сыйныфны тәмамлаганда, укучыларның белеменә , эш осталыгына һәм күнекмәләренә таләпләр:**

**Әлифба чорының ахырына белергә тиеш:**

1. Татар теленең авазларының сузык (ачык авыз символы белән бирелгән), ягъни җырлана торган аваз һәм тартык, ягъни җырланмый торган; әйткәндә, сөйләм органнарында киртә ясала/ясалмый торган авазларга бүленүен, сузыкларның калын һәм нечкә булуын, тартыкларның нечкә - калын яңгырашын сузык аваз хәрефләре белдерүен;
- сүзнең яңгыраш һәм мәгънә бөтенлегенә ия булуын;
- сүзнең иҗекләргә бүленүен, бер иҗекнең көчлерәк һәм озынрак әйтелүен;
- сөйләм авазлары язуда шартлы график символлар (түгәрәк, квадрат) яки хәрефләр белән белдерелүен;
- сүзләр предметларны, аларның билгеләрен, эш-хәрәкәтләрен белдерүләрен, ярдәмче сүзләр сүзләрне, җөмләләрне үзара бәйләү өчен хезмәт итүләрен, аларның график символларын;
- әйтмә сөйләмнең текст һәм җөмләләргә бүленүен, аларны график сурәтләп булу мөмкинлеген;
- элемент-сызыклар һәм элемент-өлгеләрнең басма һәм язма хәрефләрнең график системасының структур (төзелеш) берәмлекләре булуын;
- һәр басма һәм язма хәреф формасының тиешле урын-сан мөнәсәбәтендә урнашкан элементлардан торуын аңлый белергә тиеш.

**Уку елын  бетергәндә укучылар түбәндәгеләрне эшли белергә тиеш:**

- Гади җөмлә ахырындагы тыныш билгеләренә, җөмлә эчендәге тиңдәш кисәкләргә, эндәш сүзләргә туры килгән интонация һәм паузаларга игътибар итеп укый белергә;
- уку гигиенасын һәм китапны саклап тоту кагыйдәләрен үтәргә;
- китапларны эчтәлегенә карап аера белергә, китап, әсәр исемнәрен дөрес әйтергә;
- текст кисәкләрен төшереп калдырмыйча, таныш әкият яки хикәя эчтәлеген укытучы сораулары буенча сөйләргә;
- картина буенча бәйләнешле сөйләм төзергә;
- укылган җөмләләргә яки текстларга карата сорауларга телдән җавап бирергә;
- укыган текстның эчтәлеген сөйләргә;
- тыңланган текстка исем куша белергә.

**2 нче сыйныф**

**Уку елы башына укучылар белергә тиеш**

Укучылар текстларны дөрес, салмак, иҗекләп, минутына 30 сүз укырга;
Әсәрдә катнашучыларның сыйфатларын күрә, таба белергә;
Сүз сыйфатларын, хәрәкәт сыйфатларын күрсәтә белергә;
Әсәргә анализ ясарга.

**Уку фәнен өйрәнү нәтиҗәсендә 2 нче сыйныф укучысы таныш булырга тиеш :**

Әсәрләр, аларның авторлары.
Китапның элементлары (тышы, эчтәлеге, титул бите, иллюстрацияләр).
Текстларны дөрес, аңлаешлы итеп, минутына 1 нче яртыеллыкта 25 сүз, икенче яртыеллыкта 35 сүз укырга;
Бер үк эчтәлекне хикәяләү һәм сурәтләү формасында сөйләргә;
Хикәяләү һәм сурәтләүнең өлешләре һәм алар арасындагы бәйләнешнең үзенчәлекләрен әйтә белергә;
Хикәяләү һәм сурәтләү текстларын аера белергә;
Текстның эчтәлеген телдән һәм язмача бирә белергә;
Сюжетлы рәсемнәр буенча, күзәтүләргә нигезләнеп, хикәяләү һәм сөрәтләү характерындагы текстлар иҗат итә белергә.

**Уку техникасы**

Аңлап, дөрес һәм йөгерек уку, уку тизлеге 1 минутка 35— 45 сүздән ким булмау. Эчтән уку һәм сәнгатьле укуның башлангыч күнекмәләрен формалаштыру.

**2нче сыйныф ахырына укучы:**

текстның темасын аңдата белергә;
текстны вакыйгасы буенча өлешләргә тарката белергә;
укытучы ярдәмендә план төзи һәм шуның буенча эчтәлеген сөйли белергә;
укытучы ярдәмендә текстның төп фикерен билгели белергә тиеш.

**Ятлау өчен әсәрләр**

**Габдулла Тукай.** Туган тел. Җир йокысы.
**Бари Рәхмәт.**Кошлар киткәндә.
**Муса Җәлил.** Көз җитте.
**Зәкия Туфайлова**.Туган ил.

**Әңгәмә кору өчен якынча темалар**

*И туган тел, и матур тел!
*Күркәм, әдәпле сүзләр.
*Яшел чыршы янында.
*Әниләр бәйрәме.
*Без Татарстанда яшибез.
*Яшелчә кибетендә.

**3 нче сыйныф**

**Укучыларның сөйләм эшчәнлегенә караган таләпләр.**

**1. Тыңлап аңлау.**

- Укытучының (сыйныфташының) өйрәнгән материалга нигезләнгән сөйләмен тыңлап аңлау.
- Текстны тыңлаганнан соң, төп фикерне башкаларннан аера белү.
- Татарча сөйләмне тыңлап, сүз һәм җөмлә чикләрен билгеләү.
- Текстны тыңлап аңлау, аңа исем бирү.
- Ишеткән сөйләмнең, җөмләнең эчтәлегенә төшенү.

**2. Сөйләү.**

- Укытучы тәкъдим иткән, программада каралган темалар буенча әңгәмә кору.
- Диалогта катнашу.
- Текстның эчтәлеген сөйләү. Рәсем яки план нигезендә сөйләү.
- Укыганның эчтәлеген сораулар нигезендә сөйләү.
- Татар теленә хас булган эндәшү, мөрәҗәгать итү сүзләрен куллану.

**3. Уку.**

- Текстны (хикәя, шигырь, әкият) сәнгатьле итеп уку.
- Кыска сүзләрне тулы килеш, озын сүзләрне иҗекләп уку.
- Балалар өчен нәшер ителгән китаплар, газета-журналларны, әдәби әйтелеш нормаларын саклап, дөрес, йөгерек һәм аңлап уку.

- Укыган текстның төп фикерен аңлатып бирү.
- Этнокультура өлкәсенә караган сүзләр булган текстны аңлап уку.
- Текстта очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсенә төшенү.
- Текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү.

**Әдәби текст белән эшләү.**

- Тексттагы вакыйга яки төп персонаж буенча аңа исем таба белергә.
- Укытучының соравына тексттагы вакыйга яки эпизод белән җавап бирә белергә.
- Текстның төп фикерен үзе билгели алырга.
- Берничә текстны темасы буенча берләштерә белергә.Укылган бүлеккә план төзи белергә тиеш.

***Укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр***

- аңлы, дөрес һәм сәнгатьле уку күнекмәсе булдырып, әсәрнең исемен, төп эчтәлеген һәм авторын белергә;
- әдәби әсәр текстын "эчтән" аңлап укый белергә;
- әсәрнең темасын,идеясен билгели алырга; 1,5 биттән артык булмаган текстның эчтәлеген сөйләргә;
- текстны мәгънәви бүлекләргә бүлә һәм гади план төзи алырга;
- автор текстына нигезләнгән уртача монологик сөйләм әзерли һәм әсәр геройларын, вакыйгаларын бәяли белергә;
- программада ятлау өчен тәкъдим ителгән әсәрләрнең кимендә сигезен яттан хәтердә калдырырга;
- бирелгән темага телдән текст әзерли алырга;
- халык авыз иҗаты әсәрләреннән мәкаль, әйтем, табышмак, экиятләрдән мисаллар китерә белергә;
- әдәби жанрларны (әкият, хикәя, мәсәл) аера белергә тиеш.

**4 нче сыйныф**

**Сөйләм үстерү.**

1. Һәр сыйныфта һәр зур бүлектән соң сөйләм телен үстерү максатында сөйләшү тематикасы бирелгән. Укучылар үзләштергән материалга нигезләнеп, ирекле сөйләшү- диалог оештыру;
2. Укучыларның яшь үзенчәлекләренә туры килердәй текстлар сайлау;
3. Текстлар белән эшләгәндә, кызыклы сораулар бирү;
4. Иҗади эшләргә өйрәтү;
5. әдәби әсәрнең тел үрнәкләренә нигезләнү

**Ятлау өчен әсәрләр.**

Габдулла Тукай.Ай һәм Кояш.Фатыйма белән Сандугач.
Хәсән Туфан.Тургай нигә эндәшми?
Сибгат Хәким.Яңа шәһәрдә яшь юкә.
Шәйхи Маннур.Сагынып кайттык.

**Сыйныфтан тыш уку.**

Татар халык әкиятләре.
Фәнис Яруллин. Серле дөнья.
Хәсән Туфан шигырьләре.

**Табигать һәм без.**

**Г.Тукай.**Ай һәм кояш. Яшь агач. Фатыйма белән Сандугач. Һава. Җир. Су.
Ә.Фәйзи. Тукай
М.Галәү. Кырмыскалар.
Г.Галиев. Аю агачлар белән сөйләшә.
Г.Хәсәнов. Август.
Ш.Маннур. Сагынып кайттык.
А.Алиш.Алдакчы Наиль.
Р.Хафизова.Күгәрчен һәм малай.
Тырыш Юн Су (Кытай халык әкияте)
Р.Мөхәммәдиев.Урман карачкысы.
Л.Толстой.Арыслан белән эт.

**Озын-озак балачак.**

Н.Думави.Сарбай.
Ә.Еники.Кунакта.
Ф.Яруллин.Зәңгәр күктә ай коена.
Р.Төхфәттуллин.Сабый чаклар.
А.Тимергалин.Угры.
Н.Әхмәдиев.Чалбар.
Л.Ихсанова.Ун сумлык маҗара.
М.Кәрим.  Икебездә унөчтә булсак.
А.Линдгрен. Сугышмыйча ярамыймы соң?